РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
БУИНСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
КИЯТСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БУА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КЫЯТ
АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

2022 елның 31 гыйнвары

№ 3

Буа муниципаль районы Кыят
авыл жирлеге җирләү буенча
хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә
күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен
раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күмү һәм җирләү эше турында «Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары хакында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» 2022 елның 27 гыйнварындагы 57 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл жирлеге башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кыят авыл жирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә 6964,68 сум күләмендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта нигезендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл жирлеге Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл жирлеге җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен раслау турында» 2021 елның 29 гыйнварындагы 1 Бк/к номерлы карары 2022 елның 1 февраленнән үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карарны Кыят авыл жирлеге Уставы белән билгеләнгән тәртиптә бастырып чыгарырга һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә җирлекнең рәсми сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотам.

Буа шәһәре Кыят
авыл жирлеге Башкарма
комитеты җитәкчесе

Е.С. Корунова

ТР Буа муниципаль районы
Кыят авыл жирлеге
Башкарма комитетының
«31» гыйнвар 2022елның
3 Бк/к номерлы карарына
1нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районының Кыят авыл жирлеге
2022 елның 1 февраленнән
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| № т/б | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 00,00 |
| 2. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китереп бирү | 4364,15 |
| 3. | Мәетне ( җәсадне) зиратка илтү | 875,02 |
| 4. | Җирләү (кабер казу һәм күмү) | 1825,51 |
| Барлыгы | | 6964,68 |

ТР Буа муниципаль районы
Кыят авыл жирлеге
Башкарма комитетының
«31» гыйнвар 2022елның
3 Бк/к номерлы карарына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Кыят авыл жирлеге
2022 елның 1 февраленнән
җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәясе

| № т/б | Хезмәт күрсәтү исеме | Хезмәтләр бәясе (сумнарда) |
|---|---|---|
| 1. | Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 00,00 |
| 2. | Тәнен төрү | 788,78 |
| 3. | Җирләү өчен кирәкле табут һәм башка әйберләрне бирү һәм китереп бирү | 3475,37 |
| 4. | Мәрхүмнең мәетен ( җәсаден) зиратка илтү | 875,01 |
| 5. | Җирләү  (кабер казу һәм күмү) | 1825,51 |
| Барлыгы | | 6964,68 |